ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

30.10.2019

Казан шәһәре

**КАРАР**

№ 5-7/тэ

«ГК Транзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «ГК Транзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә әлеге карар кушымтасына туры китереп тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.10.2019 № 5-7/тэ карарына кушымта

## «ГК Транзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Тариф төре | Ел | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| | Казан шәһәре | | | | |
| 1 | «ГК Транзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, Казан шәһәренең ЕТО-1* гамәлдә булган зонасында | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2019 кадәр | 291,68 | - |
| 2 | «ГК Транзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, Казан шәһәренең ЕТО-3* гамәлдә булу зонасында | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2019 кадәр | 56,43 | - |
| 3 | «ГК Транзит» ҖЧҖ – «ТеплоЭнергоСнабжение» ҖЧҖ гамәлдә булу зонасында | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2019 кадәр | 149,94 | - |

<*> - Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2018 елның 16 августындагы 658 номерлы боерыгы белән расланган Казан шәһәренең җылылык белән тәэмин итү схемасына нигезләнеп билгеләнде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге